КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 июль г.Казань № 499

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:


Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 24 март, 192 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2011 ел, 26 июль, 604 нче; 2011 ел, 8 август, 641 нче; 2012 ел, 17 июль, 600 нче; 2013 ел, 27 март, 208 нче; 2013 ел, 1 июнь, 374 нче; 2013 ел, 6 июнь, 390 нчы; 2014 ел, 20 май, 335 нче; 2014 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 11 июль, 475 нче; 2016 ел, 21 июль, 493 нче; 2017 ел, 31 гыйнвар, 42 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 744 нче; 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы; 2018 ел, 21 май, 380 нче; 2019 ел, 26 март, 221 нче; 2019 ел, 28 май, 445 нче; 2020 ел, 5 февраль, 77 нче; 2020 ел, 6 октябрь, 909 нчы; 2020 ел, 4 ноябрь, 994 нче; 2022 ел, 28 февраль, 183 нче; 2022 ел, 16 июнь, 569 нчы; 2022 ел, 18 август, 853 нче; 2022 ел, 2 сентябрь, 953 нче; 2022 ел, 26 октябрь, 1144 нче; 2022 ел, 2 декабрь, 1277 нче; 2023 ел, 18 февраль, 152 нче; 2023 ел, 24 март, 344 нче; 2023 ел, 13 ноябрь, 1472 нче; 2023 ел, 29 декабрь, 1756 нчы; 2024 ел, 26 февраль, 97 нче; 2024 ел, 23 май, 357 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт

реестрына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре» бүлегенең беренче абзацында «465,139» саннарын «464,993» саннарына алмаштырырга;

«Әгерҗе муниципаль районы» бүлегенең «Кама-Ик [207] бүлекчәсенең карта-схемасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«





»;

«Кукмара муниципаль районы» бүлегендә:

Кукмара муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кукмара муниципаль районы




«Лубян елгасы [103] (Нократ елгасының сул як кушылдыгы)» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Лубян елгасы [103] (Нократ елгасының сул як кушылдыгы)

| | |
|---|---|
| Статусы | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан АССР Министрлар Советының 1989 ел, 24 апрель, 167 нче карары<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 644 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы |
| Җаваплы республика башкарма хакимият органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Табигать һәйкәленең озынлыгы 12,6 километр тәшкил итә.

Табигать һәйкәлен оештыру экология чылбырында иң мөһим звено буларак Лубян елгасын саклауга нигезләнгән.

Елга чагыштырмача калкулыклы тигез җир буйлап ага, аның су бүлү киңлеге җирлектә гөмбәзсыман түбә рәвешендәге күтәренке урыннардан үтә, күплечек очракта алар – сөзәк, шулай да чокырлар белән аерылган текә булганнары да очрый. Елганың асимметрияле, тар (1 – 3 километр) һәм тирән (20 – 50 метр) үзәне тау битләрендә тулысынча диярлек агач белән капланган булуы белән аерылып тора.

Елга аз сулы. Елганың туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары белән (64%). Гидрология режимы язгы ташу тирәк һәм озак вакыт су саегу белән характерлана. Ел дәвамында агымның бүленеше тигез түгел. Уртача алганда, 116 миллиметр еллык агымның 74 миллиметры язгы ташу чорына туры килә, ул гадәттә март ахырында башлана. Яз көне су йомшак һәм су саеккан вакытта – уртача каты.

Бөтерчек суалчаннарның – 10, тармакмыеклыларның – 6 һәм кысласыман ишкәгаяклыларның 3 төре, суүсемнәрнең якынча 14 төре билгеле.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин